Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Иске Көшкет авылы торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
ХАЛЫК ҖЫЕН КАРАРЫ

25 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең Иске Көшкәт авылында гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең Иске Көшкәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булмаган һәр кешедән, түбән керемле (80 яшькә җиткән) ялгыз өлкән яшьтәге пенсионерлардан, онкология авыруларыннан, Россия Армиясендә хезмәт итүчеләрдән, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны, 2023 елда Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын үзара салым суммасының 90% күләмендә ташламалар бирүдән тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү каралган.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.)

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Балтач муниципаль районы
Яңгул авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гыйльфанов